| ГЛАВА САКЛОВ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САКЛАУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛАГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 4 01.10.2022

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Саклаубаш авылында 2022 нче елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 18.1 статьясы нигезендә. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Уставы: нигезендә карар бирәм:

1. Саклаубаш авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 12 нче октябрь 2022 нчы ел 10:00 сәгатькә билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: « 2022 елда «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегендә Саклау-Баш авыл җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2021 ел, №1 карары нигезендә Саклаубаш авыл җирлеге бюджетына кергән «Саклаубаш авылында Чишмәгә материаллар сатып алу һәм төзекләндерү» нә билгеләнгән гражданнарның үзара салым акчасын Чишмә юкка чыгу сәбәпле түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә файдаланырга, шуңа бәйле рәвештә түбәндәге максатларга җибәрергә:
- “Яңа урам һәм Д.Сөләйманов урамларына материаллар алып су линиясе сузу” ?

«ӘЙЕ» “ЮК".

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга. («Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында) һәм «Интернет» мәгълүмат

– телекоммуникация челтәрендә, Саклаубаш, Өчөйле Саклау, Алга, Яңа Саклау авылларында урнашкан махсус мәгълүмат стендларында.
4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Саклаубаш авыл
җирлеге башлыгы Л.М.Габидуллина